**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Положение о комиссиях по соблюдению требований к служебному поведению государственных гражданских служащих Республики Татарстан и урегулированию конфликта интересов

1. Внести в Положение о комиссиях по соблюдению требований к служебному поведению государственных гражданских служащих Республики Татарстан и урегулированию конфликта интересов, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 25 августа 2010 года № УП-569 «О комиссиях по соблюдению требований к служебному поведению государственных гражданских служащих Республики Татарстан и урегулированию конфликта интересов» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 6 ноября 2013 года № УП-1084, от 20 августа 2014 года № УП-797, от 24 сентября 2014 года № УП-920, от 23 марта 2015 года № УП-308, от 18 марта 2016 года № УП-265, от 11 декабря 2017 года № УП-1092, от 20 декабря 2022 года № УП-905 и Указом Раиса Республики Татарстан от 23 сентября 2023 года № 667), следующие изменения:

а) подпункт «а» пункта 3 изложить в следующей редакции:

«а) в обеспечении соблюдения государственными гражданскими служащими Республики Татарстан (далее – государственные служащие) ограничений и запретов, требований о предотвращении или об урегулировании конфликта интересов, исполнения обязанностей, установленных Федеральным законом от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции», другими федеральными законами в целях противодействия коррупции (далее – требования к служебному поведению и (или) требования об урегулировании конфликта интересов);»;

б) пункт 15 дополнить подпунктом «е» следующего содержания:

«е) уведомление государственного служащего о возникновении не зависящих от него обстоятельств, препятствующих соблюдению требований к служебному поведению и (или) требований об урегулировании конфликта интересов.»;

в) пункт $16^4$ изложить в следующей редакции:

«$16^4$. Уведомления, указанные в абзаце пятом подпункта «б» и подпункте «е» пункта 15 настоящего Положения, рассматриваются подразделением кадровой службы государственного органа по профилактике

коррупционных и иных правонарушений либо должностным лицом кадровой службы государственного органа, ответственным за работу по профилактике коррупционных и иных правонарушений, которое осуществляет подготовку мотивированных заключений по результатам рассмотрения уведомлений.»;

г) в пункте $16^5$ слова «подпункте «д» пункта 15» заменить словами «подпунктах «д» и «е» пункта 15»;

д) в пункте $16^6$:

в подпункте «а» слова «подпункте «д» пункта 15» заменить словами «подпунктах «д» и «е» пункта 15»;

подпункт «в» изложить в следующей редакции:

«в) мотивированный вывод по результатам предварительного рассмотрения обращений и уведомлений, указанных в абзацах втором и пятом подпункта «б», подпунктах «д» и «е» пункта 15 настоящего Положения, а также рекомендации для принятия одного из решений в соответствии с пунктами 23, $24^3$, $24^4$, $25^1$ настоящего Положения или иного решения.»;

е) пункт $17^2$ изложить в следующей редакции:

«$17^2$. Уведомления, указанные в подпунктах «д» и «е» пункта 15 настоящего Положения, как правило, рассматриваются на очередном (плановом) заседании комиссии.»;

ж) в пункте 18 слова «подпунктом «б» пункта 15» заменить словами «подпунктами «б» и «е» пункта 15»;

з) в подпункте «а» пункта $18^1$ слова «подпунктом «б» пункта 15» заменить словами «подпунктами «б» и «е» пункта 15»;

и) дополнить пунктом $24^4$ следующего содержания:

«$24^4$. По итогам рассмотрения вопроса, указанного в подпункте «е» пункта 15 настоящего Положения, комиссия принимает одно из следующих решений:

а) признать наличие причинно-следственной связи между возникновением не зависящих от государственного служащего обстоятельств и невозможностью соблюдения им требований к служебному поведению и (или) требований об урегулировании конфликта интересов;

б) признать отсутствие причинно-следственной связи между возникновением не зависящих от государственного служащего обстоятельств и невозможностью соблюдения им требований к служебному поведению и (или) требований об урегулировании конфликта интересов.»;

к) пункт 25 изложить в следующей редакции:

«25. По итогам рассмотрения вопросов, указанных в подпунктах «а», «б», «г», «д» и «е» пункта 15 настоящего Положения, и при наличии к тому оснований комиссия может принять иное решение, чем это предусмотрено пунктами 21–$24^4$ и $25^1$ настоящего Положения. Основания и мотивы принятия такого решения должны быть отражены в протоколе заседания комиссии.».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
13 июля 2024 года
№ 539

| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2022 елның 20 декабрендәге ПУ-905 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 23 сентябрендәге 667 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләренең) коррупциягә каршы көрәшү максатларында «Коррупциягә каршы көрәшү турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча таләпләрне (алга таба – хезмәт тәртибенә куелган таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләр) үтәүне, вазыйфалар башкаруын тәэмин итүдә;»;

б) 15 пунктка түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үтәүгә комачаулык итүче ул йогынты ясый алмый торган шартларның барлыкка килүе турында хәбәрнамәсе.»;

в) $16^4$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$16^4$. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр дәүләт органы кадрлар хезмәтенең коррупциячел яисә башка төрле хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсе яисә дәүләт органы кадрлар хезмәтенең коррупциячел яисә башка төрле хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карап тикшерелә, ул хәбәрнамәләрне карап тикшерү йомгаклары буенча нигезле бәяләмәләр әзерли.»;

г) $16^5$ пунктта «15 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «15 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

д) $16^6$ пунктта:

«а» пунктчасында «15 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «15 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле йомгак, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 23, $24^3$, $24^4$, $25^1$ пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

е) $17^2$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$17^2$. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карап тикшерелә.»;

ж) 18 пунктта «15 пунктның «б» пунктчасы» сүзләрен «15 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

з) $18^1$ пунктның «а» пунктчасында «15 пунктның «б» пунктчасы» сүзләрен «15 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

и) түбәндәге эчтәлекле $24^4$ пункты өстәргә:

«$24^4$. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре йогынты ясый алмый торган шартларның барлыкка килүе һәм аның хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үти алмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын тану;

б) дәүләт хезмәткәре йогынты ясый алмый торган шартларның барлыкка килүе һәм аның хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үти алмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын тану.»;

к) 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү йомгаклары буенча һәм аны кабул итүгә тиешле нигезләр булганда, комиссия әлеге Нигезләмәнең 21–$24^4$ һәм $25^1$ пунктларында каралган карарны түгел, ә башка

карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итү өчен нигезләр һәм сәбәпләр комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелергә тиеш.».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 13 июль
№ 539